DOI: 10.26907/2311-2042-2024-22-1-180-185

# THE LAST OF THE MOHICANS

**Anis Foatovich Galimdjanov,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
anis_59@mail.ru.

**Farit Rashitovich Shakirzyanov,**
Kazan State University of Architecture and Engineering,
1 Zelenaya Str., Kazan, 420043, Russian Federation,
faritbox@mail.ru.



**Shakirzyanov Rashit Agleevich** (7.06.1949 – 22.11.2021) was a scientist in the field of structural mechanics, candidate of technical sciences (1990), head of the Methodological Office for Teaching in the Tatar Language, Honorary Worker of Higher Education of the Russian Federation (2009), Honorary Worker of Higher School of the Republic of Tatarstan (2015), laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan in the Field of Science and Technology (2009) and laureate of the Kayum Nasyri Prize.

He graduated from the Faculty of Mechanics and Mathematics of Moscow State University with a degree in mechanics in 1975. He began his teaching and scientific career in 1975 at the Kazan Civil Engineering Institute (now the Kazan University of Architecture and Engineering), where he worked all his life. He was an engineer in the Department of Strength of Materials and Theory of Elasticity of the Insti-

**Рәшит Әгълә улы Шакирҗанов** (7.06.1949 – 22.11.2021) – төзелеш механикасы өлкәсендә галим, техник фәннәр кандидаты (1990), татар телендә укыту буенча методик кабинет мөдире, РФ Югары белем бирү мактаулы хезмәткәре (2009), ТР Югары мәктәбе атказанган хезмәткәре (2015), ТРның Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе лауреаты (2009), Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты.

Казан дәүләт университеты механика-математика факультетын «Механика» белгечлеге буенча 1975 нче елда тәмамлаган. Педагогик һәм фәнни эшчәнлеген Казан инженерлык-төзелеш институтында (хәзерге Казан архитектура-төзелеш университеты) 1975 нче елда башлый һәм гомер буе шунда хезмәт куя. Институтның материаллар каршылыгы һәм сыгылмалылык теориясе кафедрасы

**Шакирзянов Рашит Аглеевич** (7.06.1949 – 22.11.2021) – ученый в области строительной механики, кандидат технических наук (1990), заведующий методическим кабинетом по преподаванию на татарском языке, Почетный работник высшего образования РФ (2009), заслуженный работник высшей школы РТ (2015), лауреат Государственной премии РТ в области науки и техники (2009), лауреат имени премии Каюма Насыри.

Окончил механико-математический факультет МГУ по специальности «Механика» в 1975 г. Педагогическую и научную деятельность начал в 1975 г. в Казанском инженерно-строительном институте (ныне Казанский архитектурно-строительный университет), где проработал всю жизнь. Инженер кафедры сопротивления материалов и теории упругости института (1975–1977), ассистент

tute (1975-1977), assistant professor in the Department of Structural Mechanics (1977-1979, 1982-1990), graduate student (1979-1982) and senior lecturer in the same department (1990-1993), later associate professor 1993-2008) and professor in the same department. In (2008-2013), he was associate professor in the Department of Mechanics (2013-2021) and in 1995-2001 head of the Methodological Office for Teaching the Tatar Language. In 1997-2014, he was also the editor-in-chief of the journal "Nauka i Yazyk" (Science and Language).

инженеры (1975–1977), төзелеш механикасы кафедрасы ассистенты (1977–1979, 1982–1990), шул ук кафедра аспиранты (1979–1982), шул ук кафедрада өлкән укытучы (1990–1993), кафедра доценты (1993–2008), шул ук кафедра профессоры (2008–2013), механика кафедрасы доценты (2013–2021). 1995–2021 нче елларда татар телендә укыту буенча методик кабинет мөдире. 1997–2014 нче елларда «Фән һәм тел» журналының баш мөхәррире.

кафедры строительной механики (1977–1979, 1982–1990), аспирант той же кафедры (1979–1982), старший преподаватель той же кафедры (1990–1993), доцент той же кафедры (1993–2008), профессор той же кафедры (2008–2013), доцент кафедры механики (2013–2021). В 1995–2001 гг. заведующий методическим кабинетом по преподаванию татарского языка. В 1997–2014 гг. главный редактор журнала «Наука и язык».

It seems only natural that every thinking Tatar, without being nationalistic, wants to see his people and his language equal in their rights among other peoples and languages. If your native language is being lost, is opposed to being widely used, it is one's sacred duty to make every effort to maintain the use of your mother tongue. One of these selfless people was Rashit Shakirzyanov who devoted his entire life to preserving his native Tatar language.

Rashit Shakirzyanov was born into a family of teachers on June 7, 1949 in the village of Yamashirma, the Vysokogorskiy Region. He graduated from 8th grade of Yamashirma School. As he wrote, "my close connections with the school and the village of Yamashirma ended in 1964. At first, I came to the village to visit my parents, talk to them and help. This place gave me vitality, and the school gave me a good upbringing and education, so I miss the village and its inhabitants, I remember them. Later, I was able to write and publish the monograph "Yamashirma maktabe – magrifat chishmase" ("Yamashirma School – a Spring of Enlightenment") about the history of my village and school, in which these feelings of mine are clearly reflected". Shortly after, his father sent him to Kazan, to School No. 15 with profound learning of mathematics. R. Shakirzyanov graduated from this high school in 1964. In the same year, he entered the Department of Mechanics of the Faculty of Mechanics and Mathematics at Kazan State University. In his second year he was drafted into the army where he served for two years, so he graduated from the university only in 1975 and was appointed as an engineer in the Department of Strength of Materials at the Kazan Civil Engineering Institute. While working in this department, he took part in the study of various theoretical and experimental properties of helicopters. He continued this research work as an assistant professor in the Department of Structural Mechanics, at the same time doing his postgraduate course.

However, his research work ran into difficulties. The results of his research were appropriated by others; after the death of his supervisor, he had to change the subject matter of his study, so in fact, R. Shakirzyanov wrote two candidate dissertations and passed two candidate exams in his specialty. He successfully defended his Ph.D. thesis on February 19, 1990 at the Dissertation Council of MGMI in specialty 05.23.17 (structural mechanics).

The winds of change began to blow. At the beginning of 1991, a movement to return the instruction in the Tatar language began in higher educational institutions. In Kazan universities, the head of this movement was Vagiz Fatkhullin, the dean of the Construction Faculty of the Construction Institute. The article "On the possibility of teaching in two languages" was added to the Institute's charter.

Naturally, when teaching technical and exact disciplines in Tatar, the first problem that arises is terminology. As you know, it basically exists, since the Tatar people are educated, well-read and work in various fields. However, at that time, these terms were found in different sources, scattered in different works, and they were to be put together and processed. Various technical problems arose, including the problem of the absence of the Tatar font on computers, they were to be made. Despite this, in fact within two years, Rashit all by himself, prepared one of the first terminological dictionaries "Ruscha-tatarcha tozelesh atamalary suzlege" ("Russian-Tatar Dictionary of Construction Terms") with a volume of more than 500 pages, with a meaningful and thorough introductory article. During these years, Rashit Shakirzyan began to actively participate in public life and became intensively involved in editorial work. In fact, it was he who developed and published the "Russian-

Tatar Oilfield Dictionary". At the same time, he created a course of lectures in his specialty and began delivering it to students.

In those years, through the efforts of Rashit Shakirzyanov and Vagiz Fatkhullin, the first popular science journal "Fan hem Tel" ("Science and Language") began to be published in the Tatar language. Its slogan and motto was "Belem-akyl-gamal" ("Knowledge-mind-action"), and articles related to various fields of science were published in it in the Tatar language. In fact, all the work of the journal - collecting articles and editing, was carried out by Rashit Shakirzyanov. Based on the materials, published in the section of the journal "Mashur Galimnerebez" ("Illustrious Scientists"), the book "Mashur Tatar Galimnere" (Illustrious Tatar Scientists) was compiled. Unfortunately, the journal ceased publication in 2013; a total of 51 issues of the journal were published.

During these years, mainly through the efforts of Rashit Shakirzyanov, the concept of "Tatar telenda yugari belem biru" ("Higher education in the Tatar language") was developed. It was made public at the 5th Republican Conference "Vuzlarda Tatar telenda ukytu problemalary" ("Problems of teaching in the Tatar language in universities"). The concept was accepted, but, unfortunately, until now it has not been implemented.

Vagiz Fatkhullin, the dean of the Faculty of Engineering, who promoted education in the Tatar language, died tragically in the autumn of 2005. At KSASU, Rashit Shakirzyanov was appointed responsible for the management of education in the Tatar language; he was made the head of the Methodological Office for Education in the Tatar Language. In 2006, a scientific and practical conference was held dedicated to the 15th anniversary of teaching in the Tatar language at KSASU. It was dedicated to the memory of V. Fatkhullin. Since the autumn of 2008, Prof. R. Nizamov, who has assumed the duties of the University Rector, has greatly helped the cause of teaching in the Tatar language.

In 2008, taking into account all his merits in various fields, Rashit Shakirzyanov was elected professor. In the same year he was given the Prize of the Republic of Tatarstan in the field of Science and Technology. In 2009, on his 60th anniversary, he was awarded the honorary title "Honored Worker of Higher Professional Education of the Russian Federation."

Preparing textbooks and lecture courses in the Tatar language continued unceasingly. Rashit Shakirzyanov was always ready to help any researcher in any field of science; he assisted them in compiling textbooks, dictionaries for their courses and organized conferences on teaching in the Tatar language. In 2019, in honor of his 70th anniversary, he was given a badge "For achievements in education", "For active and fruitful activity in training specialists with higher education in the state languages of the Republic of Tatarstan, for many years of conscientious work." However, in recent years, pressure against teaching in the Tatar language has increased; it is not obvious or explicit but noticeably felt. As Rashit wrote, "When your work is seen, recognized and appreciated, it is a great joy and pride. However, in recent years there have been a lot of losses and retreats: the main direction in which I worked sparing no effort and time – increasing the status of the Tatar language, its preservation, development, higher education teaching and conducting research work in the Tatar language – all these were subjected to strong oppression... At a meeting of the State Council this chauvinistic oppression was opposed by the only deputy – the Minister of Education E. Fattakhov. As a protest against this injustice, he quit his job. This is our real hero, a fearless and relentless national warrior!

What were the people doing at this time? Even if there were some protests, nothing went beyond words. We didn't have leaders. Faith in the rulers, obedience to them and their support has become a habit, absorbed into the blood for over hundreds of years. After all, at one time we even gave up Queen Syuyumbike to the enemy.

What are the results? Our children practically do not know the Tatar language. Now they are studying in Russian schools that provide poor quality of teaching, they are full of chauvinism and Russian Orthodoxy, giving education in a deceitful patriotic spirit. Our parents do not want to send their children to Tatar schools. As a result of this, last year we were unable to recruit a group studying in the Tatar language at KSASU. Thus, for our language and people, the prospect of not only growing, but also simply surviving is lost. It is no longer possible to endure all this; we need to take some drastic measures, pull the people out of the modern ideological emptiness and darkness, educate them and raise them to their feet.

With all of the above in mind, I have published articles and spoken in various media and newspapers, scientific collections of articles on the topic of the Tatar language proving its spiritual value at the global level. Among them are an open letter to the radio station "Echo of Moscow", an interview with the radio station "Azatlyk"

(Freedom)*[1], the articles "Tatar tele saklauga laek" ("The Tatar language deserves to be preserved") and "Kilachak tele da ul!" ("It is the language of the future!") in Issues 45 and 52 of the newspaper "Madani Zhomga" ("The Cultural Friday") of 2020."

Rashit Shakirzyanov was a selfless person who dedicated his life to the preservation and development of his native language. Unfortunately, insidious Covid took him from our ranks. I do not know other people who would do as much for the benefit of our native language as he did. As you know, when it came to preserving the Tatar language, about teaching in the Tatar language, he expressed sharp ideas, perhaps many people did not like it. However, everything he did, all his speeches were dedicated to preserving his native language, for the sake of this he was ready to do anything. His work, research works, textbooks, dictionaries on teaching technical and exact sciences in the Tatar language will serve the people for many years to come. This year, a Tatar group has reopened for students at KSASU. KFU has bilingual and multilingual groups for its undergraduates. So, don't lose hope.

**References**

1. Shakirzyanov, R. A. (2021). *Tugan telne saklau yulynda: izhat hem yazmysh* [On the Path to Preserving the Native Language: Creativity and Fate. A Monograph (in Tatar and Russian)]. F. R. Shakirzyanov. 500 p. Kazan, LLC "Alfa-K". (In Tatar)
2. *Yamashirma maktabe – magrifat chishmase* (2005) [Yamashirma School – a Spring of Enlightenment]. Monografiya. 204 p. Kazan. (In Tatar)
3. *Mashhur tatar galimnare* (2011) [Illustrious Tatar Scientists]. (Avtordashlar: A. I. Narbekov, F. R. Shakirzyanov). (Monografiya). 423 p. Kazan. Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
4. *Tatar tele saklauga hem yaklauga laek* (2020) [The Tatar Language Deserves to Be Preserved and Protected]. "Madani Zhomga". No. 45, 52, p. 11. (In Tatar)

# СОҢГЫ МОГИКАН

**Әнис Фоат улы Галимҗанов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
anis_59@mail.ru.

**Фәрит Рәшит улы Шакирҗанов,**
Казан архитектура-төзелеш университеты,
Россия, 420043, Казан ш., Яшел ур., 1 нче йорт,
faritbox@mail.ru.

Уйлый белгән, аз гына булса да, милли хисе булган һәр татар баласының үзенең халкын, үз туган телен халыклар һәм телләр арасында тигез хокуклы итеп күрергә теләве табигый хәлдер. Әгәр дә туган телең кысыла, югала (һәм югалтыла!) бара икән, моңа каршы чыгу, туган телең яшәсен өчен бөтен көчеңне кую фарыз гамәлдер. Бөтен гомерен туган телне – татар телен яшәтүгә багышлаган Рәшит Әгълә улы Шакирҗанов шундый фидакарь затлардан иде.

Рәшит Әгълә улы Шакирҗанов Биектау районы Ямаширмә авылында 1949 нчы елның 7 июнендә укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Ямаширмә мәктәбендә ул 8 нче сыйныфны тәмамлый. Үзе язганча, «минем Ямаширмә мәктәбе һәм авылы белән тыгыз элемтәм шушы 1964 елда тәмамланды. Мин авылга, башлыча, эти-әниләр янына, алар белән аралашырга һәм ярдәм итәргә кайтып йөри башладым. Бу җир миңа – яшәү көче, ә мәктәп яхшы тәрбия һәм белем биргәнгә, мин авылны һәм аның кешеләрен сагынам, искә алам. Шул хисләремне чагылдырырга тырышып, соңрак авылым һәм мәктәбем тарихын яктырткан «Ямаширмә мәктәбе – мәгърифәт чишмәсе» дигән монографияне яза һәм бастыра алдым». Аннан соң аны этисе Казандагы математиканы махсус программа белән укыта торган 15 нче мәктәпкә бирә. Урта мәктәпне Р. Ә. Шакирҗанов шунда 1964 нче елда тәмамлый. Шул ук елны ул Казан дәүләт университеты механика-математика факультетының «Механика» бүлегенә укырга керә. Икенче курстан армия сафларына алына, анда ике ел хезмәт итеп кайта, шуңа күрә университетны 1975 нче елда гына тәмамлый

[1]* Registered as a foreign agent by the Ministry of Justice of Russian Federation

һәм комиссия аны Казан инженер-төзелеш институтына материаллар каршылыгы кафедрасына инженер итеп билгели. Бу кафедрада ул вертолётларның төрле үзлекләрен теоретик һәм эксперименталь юллар белән өйрәнүдә катнаша. Бу фәнни эшен ул инде төзелеш механикасы кафедрасы ассистенты һәм шул ук вакытта аспирант булып та дәвам итә.

Фәнни эше дә киртәләргә очрый аның. Ул эшләгәнне башкалар үзләштерә, фәнни җитәкчесе вафат булганнан соң, темасын үзгәртергә туры килә. Шул рәвешле Р. Ә. Шакирҗанов ике кандидатлык диссертациясе яза, белгечлек буенча ике тапкыр кандидатлык имтиханы бирә. Кандидатлык диссертациясен 1990 елның 19 февраль көнне МГМИда (Мәскәү гидромелиорация институты) 05.23.17 (Төзелеш механикасы) белгечлеге буенча диссертацияләр яклау советында уңышлы яклый.

Үзгәртеп кору җилләре исә башлаган 1991 нче елда югары уку йортларында татарча белем бирүне кайтару буенча хәрәкәт башлана. Казан югары уку йортларында бу хәрәкәт башында төзелеш институты, шәхсән, төзелеш факультеты деканы Вәгыйз Шәйхулла улы Фәтхуллин тора. Институт уставына «ике телдә дә укыту мөмкинлеге турында» пункт өстәлә.

Билгеле, техник һәм төгәл фәннәрне татарча укытканда килеп чыккан мәсьәләләрнең беренчесе – терминология. Билгеле, алар, нигездә, бар, чөнки татар халкы китаплы, мәгърифәтле халык булган һәм төрле өлкәләрдә хезмәт куйган. Ләкин ул терминнар төрле чыганакларда таралган, һәм аларны бергә җыярга, эшкәртергә кирәк. Төрле техник проблемалар, шул исәптән ул вакытта компьютерларда татар хәрефләре булмау проблемасы да чыга, бу мәсьәләне дә хәл итәргә кирәк. Шуңа карамастан, Рәшит Әгъләм улы махсус юнәлешле сүзлекләр арасында беренчеләрдән булып, 500 биттән артык күләмдә «Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге»н ике ел эчендә әзерләп, аңа эчтәлекле, әтрафлы кереш мәкалә язып бастыруга ирешә. Шушы елларда Рәшит Шакирҗанов җәмәгать эшләрендә актив катнаша башлый, редакторлык эше белән дә актив шөгыльләнә. Шулай ук «Русско-татарский нефтепромысловый словарь» сүзлеген дә эшләп бетереп, бастырып чыгаруга ирешә. Бер үк вакытта ул үз белгечлеге буенча татарча лекцияләр курсын төзи һәм укыта башлый.

Шушы ук елларда Рәшит Шакирҗанов һәм Вәгыйз Фәтхуллин тырышлыгы белән татар телендә беренче фәнни-хәбәри басма – «Фән һәм тел» журналы чыга башлый. Аның шигаре «Белем–акыл–гамәл» була, анда татар телендә фәннең төрле өлкәләренә караган мәкаләләр басыла. Басманың эшен оештыручы, мәкаләләрне җыючы, редакцияләүче Рәшит Шакирҗанов була. Журналның «Мәшһүр галимнәребез» сәхифәсендә басылып чыккан материалларга нигезләнеп, «Мәшһүр татар галимнәре» китабы төзелә. Кызганычка каршы, журнал 2013 нче елда эшчәнлеген туктата, аның 51 саны гына дөнья күреп кала.

Бу елларда, нигездә, Рәшит Шакирҗанов тарафыннан «Татар телендә югары белем бирү» концепциясе эшләнә һәм ул «Вузларда татар телендә укыту проблемалары» дигән 5 нче Республика конференциясендә игълан ителә. Концепция кабул ителә, ләкин, кызганычка каршы, аның хәзерге вакытка кадәр тормышка ашырылганы юк.

Төзелеш факультеты деканы, татар телендә укытуны әйдәп баручы Вәгыйз Фәтхуллин 2005 нче елның көзендә фаҗигале рәвештә вафат була. КДАТУда татар телендә укытуны җитәкләү өчен җаваплы кеше һәм татарча укыту буенча методик кабинет мөдире итеп Рәшит Шакирҗанов билгеләнә. 2006 нчы елда КДАТУда татарча укыта башлауның 15 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрелә, һәм ул В. Ш. Фәтхуллин истәлегенә багышлана. 2008 нче елның көзеннән ректор вазифасына керешкән профессор Р. К. Низамов татарча укытуга бик нык ярдәм итә.

2008 нче елда, төрле юнәлештә башкарылган эшләрен исәпкә алып, Рәшит Шакирҗанов профессор итеп сайлана. Шул ук елда аңа ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге премиясе, ә 2009 нчы елда 60 яшьлек юбилеена «Россия Федерациясенең һөнәри югары белем бирү өлкәсендәге мактаулы хезмәткәре» дигән исем бирелә.

Татар телендә дәреслекләр язу, лекцияләр курсларын төзү өзлексез дәвам итә. Рәшит Шакирҗанов бер белгечлек буенча килгән галимнәрне дә кире какмый, аларга үз курслары буенча дәреслекләр, сүзлекләр төзергә ярдәм итә, татарча укыту буенча конференцияләр үткәрүдә башлап йөри. 2019 нчы елда 70 яшьлек юбилеенда аңа «Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә югары белемле белгечләр әзерләүдә актив һәм нәтиҗәле эшчәнлек, күпьеллык намуслы хезмәт өчен» дип атап, шул елның октябрендә «Мәгарифтәге

казанышлар өчен» күкрәк билгесе бирелә. Ләкин соңгы елларда татарча укытуга каршы басым көчәйде. Рәшит үзе язганча, «Эшеңне күрү, тану, югары бәяләү зур шатлык һәм горурлык инде ул. Әмма соңгы елларда зур югалтулар, артка чигенүләр дә булды: бар көчемне биреп, вакытымны кызганмыйча тырышып эшләгән төп юнәлеш – татар теленең статусын күтәрү, аны саклау, үстерү, татар телендә югары белем бирү һәм фәнни эшчәнлек алып бару юнәлеше – зур басымга дучар булды... Бу шовинистик басымга Дәүләт советы утырышында каршы чыккан бердәнбер депутатыбыз − мәгариф министры Э. Н. Фәттахов кына булды кебек. Шушы гаделсезлеккә протест йөзеннән, ул эшеннән китте. Менә кем ул безнең чын каһарманыбыз, курыкмас һәм чигенмәс милли батырыбыз!

Бу чорда халкыбыз ни эшләде соң? Кайбер протестлар булса да, сөйләнүдән узмадык. Лидерларыбыз юк. Түрәләргә ышану, аларга буйсыну һәм иярү гадәткә кергән, йөзләрчә еллар буена каныбызга сеңгән. Заманында Сөембикә-ханбикәбезне дә дошманга биреп җибәргән халык бит без.

Инде нәтиҗәләр нинди? Балаларыбыз татар телен белми диярлек. Хәзер алар сай белем бирә торган, шовинизм һәм рус православиесе аңкыган, ялган патриотик рухта тәрбияләүче мәктәпләрдә укыйлар. Ата-аналарыбыз балаларын татар мәктәпләренә бирергә теләми. Шуның нәтиҗәсендә узган ел КДАТУда без дә татар телендә укый торган төркем туплый алмадык. Шулай итеп, телебезгә, халкыбызга үсәргә түгел, сакланып калырга да перспектива бетә бара. Инде боларга түзеп торып булмый, ниндидер кардиналь чаралар күрергә, халыкны бүгенге идеологик бушлыктан, караңгылыктан чыгарырга, тәрбияләргә, күтәрергә кирәк.

Шуларны истә тотып, мин төрле массакүләм матбугат чараларында һәм газеталарда, фәнни җыентыкларда татар теленә багышланган, аның дөньякүләм дәрәҗәдәге рухи кыйммәт икәнен раслый торган мәкаләләр һәм чыгышлар ясадым. Алар арасында «Эхо Москвы» радиостанциясенә ачык хат, «Азатлык»*[1] радиостанциясенә интервью, «Мәдәни җомга» газетасының 2020 елгы 45 һәм 52 нче саннарында басылган «Татар теле саклауга лаек» һәм «Киләчәк теле дә ул!» мәкаләләрем бар».

Рәшит Шакирҗанов үзенең тормышын туган телебезне саклауга, үстерүгә багышлаган фидакарь шәхес иде. Кызганыч, мәкерле ковид авыруы аны арабыздан алып китте. Туган телебез хакына аның кадәр эшләгән шәхесләрне белмим мин. Билгеле, сүз татар телен саклау, татарча укыту турында барганда, ул кискен-кискен фикерләр әйтә иде, күпләргә бу ошамагандыр да. Ләкин аның башкарган хезмәте, чыгышлары туган телне саклауга, яшәтүгә багышланган иде, аның хакына ул теләсә нинди адымга барырга әзер иде. Техник һәм төгәл фәннәрне татарча укытуга багышланган эшләре, фәнни хезмәтләре, дәреслекләре, сүзлекләре аның әле күп еллар халкыбызга хезмәт итәр. Быел КДАТУда татар төркеме кабат ачылды. КФУда билингваль һәм полилингваль төркемнәр бар. Димәк, өметне югалтмаска кирәк.

**Әдәбият**


1. Шакирҗанов Р. Ә. Туган телне саклау юлында: иҗат һәм язмыш: Монография (татар һәм рус телләрендә) / Ф. Р. Шакирҗанов. Казан: ООО «Альфа-К», 2021. 500 б.
2. Ямаширмә мәктәбе – мәгърифәт чишмәсе (монография). Казан, 2005. 204 б.
3. Мәшһүр татар галимнәре (монография) / автордашлар: А. И. Нарбеков, Ф. Р. Шакирҗанов. Казан: Тат. кит. нәшр., 2011. 423 б.
4. Татар теле саклауга һәм яклауга лаек // «Мәдәни җомга» газетасы. 2020. № 45, 52. – 11 б.


[1]* РФ Юстиция министрлыгы тарафыннан иноагент дип танылган.
* Признан иноагентом Министерством юстиции РФ.